ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында.
3. «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 354-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 356-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 31 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 358-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль

вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 362-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Татарстан Республикасы территориясендә аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында» 351-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 361-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.

10. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.

11. Вәкаләтләре туктатылган Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы таныклыгы турында.

12. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

13. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 195018-8 номерлы федераль закон проекты турында (тимер юллар буенча билгеләнмәгән урыннарда йөргән өчен салына торган административ штрафлар күләмен арттыру өлешендә).

14. «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 49 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында (кисәтүдә күрсәтелгән

таләпләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар хакында мәгълүмат тапшыру өлешендә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 9 декабре
№ 1717-VI ДС